**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

**2018 елның 18 мае** **№84**

**Чирмешән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгәне өчен пенсияга чыкканда бер тапкыр бүләкләү һәм Чирмешән авыл җирлегендә муниципаль вазифада эшләгән затларга муниципаль вазифадан пенсияга чыкканда, бер мәртәбә акчалата бүләкләү тәртибе турында**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллек органы депутаты, җирле үзидарә сайлаулы органы әгъзасың, җирле үзидарә органың сайлаулы вазыйфаи затның вәкаләтләрен башкару гарантияләре турында" 2009елның 12 февралендәге 15-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1.Расларга:

-Чирмешән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгәне өчен пенсияга чыкканда бер тапкыр бүләкләү тәртибе турында нигезләмәне (1 номерлы кушымта);

-Чирмешән авыл җирлегендә муниципаль вазифада эшләгән затларга муниципаль вазифадан пенсияга чыкканда бер мәртәбә акчалата бүләкләү тәртибе турында нигезләмәне (2 номерлы кушымта).

2."Муниципаль вазифадан пенсияга чыкканда, бер мәртәбә акчалата түләү тәртибе турында" 2016 елның 12 февралендәге Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар официаль порталында һәм Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең Уставы нигезендә махсус мәгълүматлар стендында бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чирмешән авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Чирмешән авыл җирлеге башлыгы** **А.Т. Зиннатуллин**

**2018елның 18 маендагы**
**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы**
**Чирмешән авыл җирлеге**
**Советы карарына**
**1 номерлы кушымта**

**Чирмешән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгәне өчен пенсияга чыкканд бер тапкыр бүләкләү тәртибе турында**
**нигезләмә**

1.1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренә (алга таба- муниципаль хезмәткәр) тиешле еллар эшләгәне өчен пенсияга чыгып, шул эштән киткәндә, муниципаль хезмәт буенча 15 ел стажы булган очракта аңа бер тапкыр шушы муниципаль хезмәт вазифасы буенча 5 тапкыр айлык акчалата содержание түләнә. Муниципаль хезмәт вазифасында муниципаль хезмәт тәҗрибәсе 15 ел булса, һәр киләсе тулы ел өчен 0,5 өстәмә акчалата содержание түләнә, ләкин әлеге бүләкләү күләме муниципаль хезмәткәрнең ун акчалата содержаниядән артмаска тиеш. Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт эшеннән киткән көннән билгеләнә.

Әлеге нигезләмәнең максаты өчен тиешле еллар эшләгәне өчен пенсияга чыгу “Иминият пенсияләре турында” Федераль законның 8 нче статьясы 1нче өлеше нигезендә иминият пенсиясе алу хокукы бирүче яшькә җитеп яисә иминият пенсиясен алдан билгеләнеп яки инвалидлык буенча иминият пенсиясе билгеләнеп муниципаль хезмәттән китүне аңлата. Гаепле гамәлләр белән бәйле рәвештә муниципаль хезмәттән киткән очракта муниципаль хезмәткәр бүләкләнми.

1.2. Бер тапкыр бүләкләүнең күләмен билгеләгәндә, айлык акчалата содержаниегә вазифа өчен хезмәт хакы, сыйнфый дәрәҗәсе өчен хезмәт хакы, хезмәт хакына махсус шартлар өчен айлык өстәмә түләү кушыла.

1.3. Әлеге нигезләмәдә каралган бер тапкыр бүләкләү турында карар муниципаль хезмәткәрнең тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле эштән китү турында җирле үзидарә органы боерыгы белән бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

1.4. Тиешле елларда эшләгән өчен пенсиягә чыкканда, бер тапкыр бүләкләүне муниципаль хезмәткәр эштән китү алдыннан хезмәт иткән җирле үзидарә органы түли.

1.5. Тиешле елларда эшләгән өчен пенсиягә чыкканда, бер тапкыр бүләкләү бары бер тапкыр гына түләнә. Әгәр гражданин тиешле елларда эшләгән өчен пенсиягә чыкканнан соң муниципаль хезмәткә керсә һәм алга таба муниципаль хезмәттән китсә, әлеге нигезләмәдә каралган бер тапкыр бүләкләү кабат түләнми.

1.6. Бер тапкыр бүләкләү Чирмешән авыл җирлеге бюджеты түләнә.

1.7. Бер тапкыр бүләкләү күләмен билгеләү өчен Чирмешән авыл җирлеге Башкарма комитетына түбәндәге документлар тапшырыла:

муниципаль хезмәткәрнең айлык содержаниясе турында белешмә;

җитәкче һәм кадрлар хезмәте тарафыннан раслаган муниципаль хезмәттәге эш тәҗрибәсе турында белешмә;

кадрлар хезмәте раслаган хезмәт кенәгәсе һәм хәрби билеты;

сыйнфый дәрәҗә бирелү, муниципаль хезмәткәрнең айлык содержаниясенә кергән өстәмә түләүләр турында боерыклардан күчермәләр;

муниципаль хезмәткәрнең законнар нигезендә эш тәҗрибәсен билгеләү өчен башка документлар.

1.8. Җирле үзидарә органы документларны әлеге Нигезләмәнең 1.7 пункты буенча муниципаль хезмәткәре тиешле елларда эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән эштән китүенә 30 календарь көн ала тапшырырга тиеш.

1.9. Башкарма комитет җирле үзидарә органы документлар тапшырганнан соң 20 көн эчендә җирле үзидарә органына муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр түләү буенча, бюджет ассигнованиясе һәм бюджет лимитлары турында хәбәрнамә бирә яки җирле үзидарәгә бер тапкыр бүләкләү өчен акча бирүне кире кага.

Башкарма комитет әлеге Нигезләмәнең 1.7 пункты буенча барлык документлар җыелып бетмәсә, җирле үзидарә органына акча бирүдән баш тарта.

1.10. Җирле үзидарә органы күрсәтелгән хәбәрнамәләр нигезендә, муниципаль хезмәткәргә тиешле елларда эшләгән өчен бер тапкыр бүләкләү түли.

**2018елның 18 маендагы**
**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы**
**Чирмешән авыл җирлеге**
**Советы карарына**
**2 номерлы кушымта**

**Чирмешән авыл җирлегендә муниципаль вазифада эшләгән затларга муниципаль вазифадан пенсияга чыкканда бер мәртәбә акчалата бүләкләү тәртибе турында нигезләмә**

1.1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегендә муниципаль вазифада даими рәвештә эшләгән затларга шул эштән китеп, пенсиягә чыкканда, "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллек органы депутаты, җирле үзидарә сайлаулы органы әгъзасың, җирле үзидарә органың сайлаулы вазыйфаи затның вәкаләтләрен башкару гарантияләре турында" 2009елның 12 февралендәге 15- ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә пенсиягә өстәмә түләү хокукы булганда, ун айлык акчалата түләү күләмендә булган бер мәртәбә акчалата бүләкләү түләнә.

1.2. Айлык акчалата бүләкләү күләме, "Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегендә даими рәвештә үз вәкаләтләрен башкаручы муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәткәрләрен, җирле үзидарә вазифасына сайланган депутатлар хезмәтен бәяләү турында" Нигезләмәсе буенча билгеләнә.

1.3. Бер тапкыр акчалата бүләкләү муниципаль вазифаны башкарган зат эшләгән җирле үзидарә органы тарафыннан түләнә.

1.4. Бер тапкыр бүләкләү күләмен билгеләү өчен, җирле үзидарә органы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Башкарма комитетына түбәндәге документлар тапшыра:

муниципаль вазифада эшләгән затны, пенсиягә чыгу сәбәпле, бер мәртәбә акчалата бүләкләү турында карар;

муниципаль вазифада эшләгән затка айлык акчалата түләү күләме турында белешмәсен;

җирле үзидарә җитәкчесе һәм җирле үзидарәнең кадрлар хезмәте раслаган муниципаль хезмәттәге һәм муниципаль вазифадагы эш тәҗрибәсе турында белешмәне;

җирле үзидарәнең кадрлар хезмәте раслаган хезмәт кенәгәсе һәм хәрби билетын;

муниципаль хезмәткәрнең законнар нигезендә эш тәҗрибәсен билгеләү өчен башка документлар.

1.5. Җирле үзидарә органы документларны әлеге Нигезләмәнең 1.4 пункты буенча, муниципаль вазифада эшләгән зат пенсиягә чыгу сәбәпле, бер мәртәбә акчалата бүләкләү турындагы карарны 5 календарь көн эчендә тапшырырга тиеш.,

1.6. Башкарма комитет җирле бюдҗеттан акча бүлеп бирү турында карар кабул ителгәннән соң 20 көн эчендә җирле үзидарә органына бер тапкыр түләү буенча, бюджет ассигнованияләре һәм бюджет лимитлары турында хәбәрнамә бирә

1.7. Җирле үзидарә органы күрсәтелгән хәбәрнамәләр нигезендә, муниципаль вазифада эшләгән затка бер тапкыр бүләкләү түли.

1.8. Бер тапкыр бүләкләү бер тапкыр гына түләнә.